**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«28» июнь 2019 ел** **Калмаш авылы** **№5/2**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендәге 7/4 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ санлы Федераль законның 1 маддәсе 13 пункты «б» пунктчасы, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Калмаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1.Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендәге 7/4 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге нигезләмәнең 3.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Гражданнар җыены торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Әгәр торак пунктта әлеге торак пункта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы берүк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган срокта этаплап үткәрелә. Шул ук вакытта гражданнар җыенында элегрәк катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый. Әгәр гражданнар җыены карары өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Калмаш авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

5.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Калмаш авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Р.К.Габдуллина